| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА Большекляринского** сельского поселения ***Камско-Устьинского*** муниципального района | | ***Кама Тамагы*** муниципаль районы **Олы Кариле** авыл җирлеге **БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ** |


| ул. Советская, 9,с. Большие Кляри, 422837<br>тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42<br>ОКПО 93064636, ОГРН 1061672003403<br>ИНН/КПП 1622004605/162201001 | Совет урамы, 9,Олы Кариле авылы, 422837,<br>тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42<br>ОКПО 93064636, ОГРН 1061672003403<br>ИНН/КПП 1622004605/162201001 |
|---|---|


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.09.20118ел. № 7

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел, № 131 Федераль законның 22, 56 статьялары нигезендә- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» ФЗ, «җирле референдум турында» 24.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрүне түбәндәге мәсьәлә буенча алып барырга: «2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы: * Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге; * җирлекне төзекләндерүне оештыру; * каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру; * халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру; * янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын оештыру. ӘЙЕ ЮК»

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: - ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1; - ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында;-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат

стендларында халыкка җиткерергә; Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

**Җитәкчесе** **Ф.Г.Гарифуллин**